**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Тархан авыл җирлегенең Олы Тархан торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**10 декабрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Тархан авыл җирлегенең Олы Тархан торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Олы Тархан авыл җирлегенең Олы Тархан торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр, I һәм II төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, ирektән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Олы Тархан авылы эчендәге юлларны төзекләндерү;
- Олы Тархан авылында буаны төзекләндерү;
- Олы Тархан авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, ятырткычлар һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру;
- Горький урамы буенча Олы Тархан авылында урнаштыру өчен вазоннар сатып алу.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **А.М. Айзатуллов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Тархан авыл җирлеге башлыгы** **А.М. Айзатуллов**